ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 385-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 385-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1845-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин,
М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелгән

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 5 өлешендәге 10 пунктында «б» пунктчасында» сүзләрен «а» һәм (яисә) «б» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 77 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$2^1$ . Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктының «в» пунктчасындагы дүртенче абзацында каралган нигезләмә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында 2021 елның 1 апреленә кадәр төзелгән килешүләр нигезендә

проектларны гамәлгә ашыра торган һәм Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә чыгымнар каплый торган оешмаларга карата кулланылмый.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатыннан эшләнде.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләү турында» Федераль законның 30 статьясындагы 8 өлешен үз көчен югалткан дип тану хакында» 2022 елның 21 ноябрендәге 453-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) белән «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларына дәүләт ярдәме чараларын бирү шартларына кагыла торган аерым нигезләмәләре төгәлләштерелде.

Федераль законда, шулай ук, Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы 2021 елның 1 апреленә кадәр төзелгән килешүләр нигезендә проектларны гамәлгә ашыра торган оешмаларга карата салымнар һәм җыемнар өлкәсендә федераль органның проектны гамәлгә ашыручы оешманың фактта тотылган чыгымнар күләмен бозып күрсәтү фактлары ачыкланмау (ачыклану) турында, шулай ук фактта тотылган чыгымнар күләмен билгеләүнең дөреслеге мәсьәләсе буенча чыгарылган үтәлмәгән дәлилләнгән фикерләрнең булмавы (булуы) хакында бәяләмә тапшыру шарты кулланылмый.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертергә тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.